ШИМБӘ
9
ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 7 (6729)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРЕНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ

ТРАКТОРЛАРГА РЕМОНТ ТЕМПЫН КӨЧӘЙТЕРГӘ

Үткән көз республикабыз колхозларында туңга сөрү планы үтәлә алмый калды. Димәк, сабан игеннәре чәчеләчәк җирләрнең күп кенә өлешен яз көне сөрергә туры киләчәк. Бу хәл бер үзе генә дә быел тракторларны язгы чәчүгә әзерләү эшенә аеруча җитди игътибар бирүне таләп итә. Хәзер язгы чәчүгә әзерлекнең барлык буыннарында эшне киң җәелдерү белән беррәттән, тракторларга ремонт ясауда да темпны күп тапкыр көчәйтергә, ремонтның сыйфатын яхшыртырга кирәк. Чөнки ремонт һаман да бик акрын бара. Бу, язгы чәчүгә әзерлек эшләрендә иң зур кимчелекләребезнең берсе булып исәпләнергә тиеш.

Чыннан да, декабрьның 25 енә республикабыз МТС ларында тракторларга ремонт ясау планы 24 процентка үтәлгән иде. Аннан соңгы 5 көнлек бары 8,2 процент үсеш бирде. Бу үсеш безне, әлбәттә, һич тә канәгатьләндерә алмый.

Дөрес, бу 5 көндә кайбер МТС лар эштә шактый текә борылыш ясауга ирештеләр. Мисал өчен Апас районының Ишеево МТС коллективын алырга була. Бу МТС соңгы 5 көндә ремонт планының үтәлешендә 17 процентка үсеш бирде. Дүртенче квартал планын 145 процентка, еллык планын 75 процентка үтәде.

Билгеле, барлык МТС ларыбызда да Ишеево МТС ы коллективы кебек эшләргә мөмкинлек бар иде һәм хәзердә дә бар. Тик ул мөмкинлектән файдалана белергә, эшне сугыш вакыты таләп иткәнчә большевикларча оештырырга гына кирәк.

Кызыл юл МТС ын алыйк. Бу МТС Ишеево, Нөркәй, Тымытык, Мөслим һәм ремонтны уңышлы алып баручы башка МТС ларыбыз кебек үк эшли аламы соң? Әлбәттә, эшли ала. Моның өчен Кызыл юл МТС ында нәрсә җитешми соң? Тик МТС директоры Сөләйманәвның һәм МТС ның башка җитәкчеләренең тракторларга ремонт ясау кебек гаять әһәмиятле эшкә карата үзләрендә тиешле җаваплылык сизүләре җитешми. МТС ның өлкән механигы иптәш Нигъмәтҗанов ремонтның нормаль барышына эш көчләренең җитәрлек булмавы тоткарлык ясый, ди. Ул бу турыда адым саен зарланып йөри. Ә шул ук вакытта ремонтта катнашырга тиешле күп кенә тракторчылар (Шәрифуллин, Галимуллина, Насыйбуллина һ. б.) ремонт эшендә катнашмыйча бөтенләй тик йөриләр. Ремонтта эшләүчеләр арасында да прогул ясаучылар шактый. МТС та тик декабрь аенда гына да 1.000 сәгатькә якын прогул ясалган. Ә МТС җитәкчеләре бу коточкыч кимчелеккә карата һаман да килешүчәнлек күрсәтеп килүдә дәвам итәләр. Прогул ясаучылардан беркем дә дип әйтерлек, тиешле законнар тәртибендә, суд җаваплылыгына тартылмаганнар. Шулай ук тракторчылар арасында масса-аңлату эшләре дә алып барылмый. Шулай булгач, Кызыл юл МТС ында тракторларга ремонт ясау эше ничек итеп нормаль барсын инде!

Кызыл юл МТС ындагы бу кимчелекләр, ремонт планын һаман да әле бары 4 процентан 8 процентка кадәр генә үтәгән Макыл, Әлки, Тат. Ялтан, Тат. Ходяш һәм башка МТС ларда да бар.

Тракторларга ремонт ясауны үз агымына кую—зур җинаять. Чөнки ул быелгы югары иген уңышы өчен көрәш эшенә зур зарар китерә. Ремонт темпын күп тапкыр көчәйтергә кирәк. Ремонтта нәсезлекне тәмам бетерергә, ремонтның сыйфаты өстеннән һәм ремонт графигының вакытында үтәлүе өстеннән нык контроль урнаштырырга кирәк. Ремонт шулай үткәрелергә тиеш ки, язгы чәчүдә барлык тракторларның да һичбер аварияcез, сәгать механизмы кебек төгәл эшләүләре тәэмин ителерлек булсын. Кайбер МТС җитәкчеләре тракторларга ремонт ясау өчен запас частьлар һәм башка материаллар җитәрлек булмаудан зарланалар. Бу—эшлексезлектән башка нәрсә түгел. Сугыш вакытында бу яки теге әйбер җитешми дип зарланып йөрү җебегәнлек ул. Һәрнәрсәне, шулай ук ремонт эшендә дә кирәкле барлык әйберләрне һәрбер МТС җитәкчесе урында табарга һәм әзерләргә тиеш.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

8 нче январьда, каты сугышлардан соң, безнең гаскәрләр ЗИМОВНИКИ шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Дәүләт Оборона Комитеты Председателе иптәш СТАЛИНГА

Татарстан АССР ның Октябрь районы колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары Сезнең тарихи докладыгыз һәм приказыгыз белән рухланып, иптәш Сталин, кыска гына срок эчендә «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә үзләренең саклык акчаларыннан 2.538 мең сум җыйдылар һәм Дәүләт банкысына тапшырдылар. Шуның өстенә, 1942 нче ел уңышыннан планнан тыш колхозлардан һәм колхозчыларның үз запасларыннан Кызыл Армия фондына 12.566 пот һәм промышленность эшчеләренә 4.000 пот ашлык тапшырылды. Акча, ашлык һәм ит керү дәвам итә, һәм бу эш тыл белән фронтның җимерелмәслек сугышчан бердәмлеге билгесе астында үтә. Немец фашист бандитларны тизрәк тар-мар итү өчен безнең районның колхозчылары бернәрсәне дә кызганмыйлар.

ЯМКОВ,

ТАССР, ВКП(б) ның Октябрь райкомы секретаре.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты секретаре иптәш МИХАЙЛОВКА

Кызыл Армия өчен кораллар төзүгә 181.657.428 сум акча, сугышчылар һәм партизаннар өчен азык һәм бүләкләр җыйган комсомолецларга, яшьләргә, пионерларга һәм мәктәп балаларына минем кайнар сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен, аларга эшләрендә уңышлар теләвемне тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

ФРУНЗЕ

Кыргызстан КП(б) Үзәк Комитеты секретаре иптәш ВАГОВКА

Кыргызстан Совет Социалистик республикасының «Кыргызстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә 85 миллион сум акча җыйган һәм промышленность предприятиеләре һәм шәһәр халыклары өчен 150 мең поттан артык авыл хуҗалыгы продуктларын дәүләт бәяләре буенча тапшырган колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

ЧЕБОКСАР

ВКП(б) ның Чувашстан өлкә комитеты секретаре иптәш ЧАРЫКОВКА

Чувашстан Автономияле Совет Социалистик республикасының «Чувашстан колхозчысы» һәм «Чувашстан тракторчысы» исемле танклар колонналары төзүгә 31.552.000 сум җыйган колхозчыларына, колхозчы хатын-кызларына һәм тракторчыларына минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Карел-Фин ССР КП(б) Үзәк Комитеты секретаре иптәш КУПРИЯНОВКА

Карел Фин Совет Социалистик республикасының «Карельский колхозник» исемле танклар колоннасы төзүгә 3 миллион сум җыйган колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

БАКУ

Азербайжан КП(б) Үзәк Комитеты секретаре иптәш БАГИРОВКА

Азербайжан Совет Социалистик республикасының «Азербайжан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә 81.020.000 сум җыйган һәм дәүләт йөкләмәләрен үтәгәннән соң Кызыл Армия фондына 140.000 пот ашлык биргән колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

УФА

ВКП(б) ның Башкортстан өлкә комитеты секретаре иптәш ЗАДИОНЧЕНКОГА

Башкорстан Автономияле Совет Социалистик республикасының «Башкорт истребителе» исемле сугыш самолетлары истребительләр төзүгә 87.250.000 сум җыйган колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

ЕРЕВАН

Әрмәнстан КП(б) Үзәк Комитеты секретаре иптәш АРУТИНОВКА

Әрмәнстан Совет Социалистик республикасының «Әрмәнстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзүгә 38 миллион сум җыйган һәм дәүләт йөкләмәләрен үтәгәннән соң җыеп, Кызыл Армия фондына 84 мең пот ашлык, бәрәңге һәм башка авыл хуҗалыгы пордуктлары биргән колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына минем туганнарча сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

Москва, Кремль, Иосиф Виссарионович СТАЛИНГА

Мөхтәрәм Иосиф Виссарионович!

Сезнең даһи җитәкчелегегездә Кызыл Армия Ватаныбызның изге чикләреннән дошманны җиңүле рәвештә куа. Гомуми җиңү эшенә һәрбер патриот үзеннән өлеш кертергә тиеш. Чиркәү безнең кораллыбызның җиңүен теләп гыйбадәт кыла, бу—дингә ышанучылар күрсәткән рухани ярдәм. Мин дә, архипастырь буларак, гыйбадәт кылам. Ләкин эш белән беркетмәгәндә гыйбадәт җансыз. Бүген минем тарафтан оборона фондына кертелгән вклад минем эшлекле ярдәмем булсын. Мин үземнеке булган, 500.000 сумнан артык тора торган панагиямне Дәүләт банкысына керттем. Минем инициативама ияреп, динне яңартучы православие чиркәве руханилары үзләренең кыйммәтле әйберләрен кертәләр. Москва епархия идарәсе самолетлар сатып алуга 70.000 сум кертте. Бу әле җиңүче Ватаныбызга чиркәүнең эшлекле ярдәменең башлануы гына. Мөхтәрәм юлбашчыбыз, азатлык, хаклык һәм туганнарча мәхәббәт принциплары бөтен дөньяда кояш кебек балкып торсын өчен алла сезнең тормышыгызны озак һәм озак еллар сакласын.

СССР ның динне яңартучы православие чиркәүләренең первоиерархы Александр Иванович ВВЕДЕНСКИЙ.

УЛЬЯНОВСК

СССР ның динне яңартучы православие чиркәвенең первоиерархы Александр Иванович ВВЕДЕНСКИЙГА

Кызыл Армия турында кайгыртучанлык күрсәткән өчен Сезгә, Александр Иванович, һәм динне яңартучы православие рус чиркәвенең руханиларына рәхмәт.

Минем сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен кабул итегез.

И. СТАЛИН.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ (Ленинград фронты). Рәсемдә: өлкән лейтенант И. И. Таран (уңда) командалыгындагы сугышчылар махсус задание башкаралар.
ТАСС фотохроникасы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

8 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

8 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр Түбән Дон районында, Үзәк фронтта һәм Төньяк Кавказда элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең частьлар, штурм группалары булып хәрәкәт итеп, дошманның ныгытмаларын җимерделәр. Дошманның 11 ДЗОТ ы, 7 блиндажы алынды һәм 120 гитлерчы кырып ташланды.

Сталинградтан төньяк-көнбатыштарак совет разведчиклары немецларның окопларына бәреп керделәр, 60 гитлерчыны юк иттеләр һәм пленныйлар алдылар.

* * *

Түбән Дон районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Дошман артиллерия уты белән, танкларның һәм мотопехотаның контратакалары белән совет гаскәрләрен туктатырга маташа. Безнең гаскәрләр, гитлерчыларның каршылык күрсәтүен сындырып, немецларның җанлы көчләрен һәм техникаларын юк итәләр һәм алга баралар. Совет очучылары һавадан куәтле ударлар белән дошман орудиеләренең һәм миномётларының утын бастырдылар. Шул вакытта безнең танклар пехота десанты алып атакага киттеләр, немецларның 2 батальонын тар-мар иттеләр һәм халык яши торган пунктны алдылар. Икенче бер участокта безнең частьлар немецларның 9 танкысын җимерттеләр һәм дошманны халык яши торган бер пункттан бәреп чыгардылар. 4 орудие, 7 миномет, бер радиостанция кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр үзләре алган позицияләрдә ныгыдылар һәм аерым участокларда дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак районда дошманның танклары һәм пехотасы безнең гаскәрләрнең позицияләренә контратака ясарга маташканнар иде. Н-че берләшмәнең сугышчылары немецларның 14 танкысын, 800 гә якын дошман солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр һәм гитлерчыларны баштагы позицияләренә чигенергә мәҗбүр иттеләр.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга киттеләр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Н-че берләшмәнең сугышчылары 11 орудие, 26 миномет һәм 23 пулемет кулга төшерделәр. Төнлә белән безнең бер подразделениебез сиздермичә генә дошман окопларының якынына ук тупланды, ә икенче подразделение дошманның тылына үтеп керде. Безнең сугышчылар немецларга бер үк вакытта фронттан да һәм тылдан да атака ясадылар һәм аларның сугышчан тәртипләрен җимерделәр. Сугыш кырында дошманның 100 дән артык үле гәүдәсе калды. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Витебск өлкәсе районнарыннан берсендә хәрәкәт итүче партизаннар отряды үзләренә немецларның һөҗүм итәргә әзерләнгәнлекләрен белгәннәр. Разведка җәза отрядының саны күпме икәнлекне, шулай ук немецларның кайчан һәм кайсы урынга удар ясарга уйлаганлыкларын белгән. Партизаннар гитлерчылардан алданрак өлгерергә карар биргәннәр. Совет патриотлары кинәт һөҗүм ясап немецларның җәза экспедициясен тар-мар иткәннәр. Бу сугышта немецларның 83 солдаты үтерелгән һәм 40 ы яраланган. Витебск партизаннарының икенчебер отряды дошманның 3 хәрби эшелонын юлдан чыгарып аударган. 3 паровоз, 8 вагон һәм 18 платформа җимерелгән. Поездларның һәлакәте вакытында 150 дән артык гитлерчы үлгән.

* * *

Югославия партизаннары Теслич шәһәрен алганнар. Бик каты сугышта немецларның 2 батальон пехотасы тар-мар ителгән. Бик күп гитлерчылар плен алынган, төрле калибрдагы 9 орудие һәм башка трофейлар кулга төшерелгән. Партизаннарның ике отряды Турека һәм Школяна исемле халык яши торган пунктларга һөҗүм иткәннәр һәм берничә дистә итальян солдатларын һәм офицерларын кырып ташлаганнар. Теслич—Добой юлында патриотлар дошманның 3 хәрби эшелонын һәм бер бронепоездын юлдан чыгарып аударганнар

БРОНЕБОЙЩИК КУДРЯШЕВ ТАНКНЫ ҖИҢДЕ

ҮЗӘК ФРОНТ. (ТАСС ның махсус хәбәрчесеннән). Бу вакыйга Великие Лукидан ерак кына түгел биеклекләрдән берсендә булды. Безнең гаскәрләр тарафыннан кысрыклантан немецлар мөһим тактик чикне калдырып киттеләр, ләкин икенче көнне, яңа көчләр китереп, контратака ясадылар. Алдан 6 танк килә иде.

Биеклекнең итәкләрендә һәм аның өстендә, тирән окопларга урнашкан хәлдә, безнең бронебойщиклар дошманның якынлашуын көтәләр иде. Кызылармеец Кудряшев дошман машиналарына беренче булып атып җибәрде. Аның сигналы буенча башка расчетлар да ут ачтылар. Броня тишә торган 3 пуля немецларның бер танкысын яндырды, ул тулы тизлеккә килә торган җиреннән туктап калды. Куе төтен арасыннан ялкын телен сузды. Танк янды. Аның экипажыннан бер генә кеше дә котылып кала алмады. Озак та үтмәде, расчетлардан берсе немецларның икенче машинасын яндырды. Ләкин калган машиналар безнең сугышчыларга таба килүләрен дәвам итәләр иде.

Артиллерия батареясы ут ачты. Дошман танклары туктадылар. Ләкин алардан берсе безнең алты кырыебызга үтен керә алды. Ул туп-туры бронебойщик Кудряшев окопы өстенә ыргылды. Кудряшев атарга өлгерә алмады, машина аның окопы өстенә килеп менде. Бронебойщик тиз генә йомарланып окопка сыенды. Окоп караңгыланды. Балчыклар ишелде. Дошман танкысы танкка каршы ата торган мылтыкны сытып үтте.

Кудряшев кулына пистолетын алды да күз ачып йомганчы окоптан чыгып дошман машинасының өстенә менеп утырды. Бөтен экипаждан бер үзе исән калган немец танкисты, совет бронебойщитын сытып үттем, дип уйлап булса кирәк, люкны ачты. Ә Кудряшев пистолеттан атып аны әйләндереп төшерде. Шулай итеп, безнең батыр бронебойщик Кудряшев бер ялгызы немец танкысына каршы көрәште һәм җиңеп чыкты.

И. ДЕНИСОВ.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Фронт һәм тыл сугышчылары арасында элемтә

«Сталинец» газетасы завод коллективы белән фронтовиклар арасындагы элемтәне яхшырту буенча бик яхшы эш башлап җибәрде. Бу элемтә газета битләрендә аеруча ачык күренә.

Узган елның март аенда Н-че завод эшчеләре белән фронтовиклар арасында ярыш башланган иде. Хәзер бу ярыш көннән-көн киңәя һәм ул массовый күренеш булып китте. Иптәш Абусалимов болай дип яза:

—Без тылның эшенә сокланабыз. Без хәтта иң авыр моментларда да аның эшен хис итәбез. Без һәрвакыт тук, өс-баш киемнәре җитәрлек һәм сугыш припаслары белән кирәгенчә тәэмин ителгәнбез.

Яшь эшче Надя Кривоборская башта сменага өч норма үти иде, соңыннан ул моны дүрткә, бишкә һәм хәтта алтыга кадәр җиткерде.

Орденлы Н-че часть сугышчылары һәм командирлары Абусалимов, Гашин, Дәүләтов, Зудко, Кочеров иптәшләр Надя Кривоборскаяга шушындый котлау телеграммасы җибәрделәр: «Надя Кривоборскаяның производстводагы гүзәл уңышлары турында «Сталинец» газетасыннан укып белгәннән соң без аны чын күңелдән котлыйбыз, аңа үзебезнең сугышчан фронт сәламебезне җибәрәбез һәм производствода аның яңа уңышларга ирешүен һәм аңа сәламәтлек телибез!».

Завод коллективы фронтовикларга хатын-кызлардан шоферлар әзерләгәнлекләрен, бу кадрларның, Ватаныбыз беренче чакыру белән үк, фронтка барырга әзер торуларын хәбәр итте.

Моңа җавап итеп лейтенант Черкашин беренче сугышларда ук 20 немецны юк итүне, дошманның станоклы пулемет расчетын сафтан чыгаруны үз өстенә алды һәм яшь эшче—стахановчы Рая Каптюшинаны ярышка чакырды.

Рая Каптюшина бу хатны бригададагы эшчеләр белән укып чыкты һәм үзенең дусы Настя Христофорова белән берлектә, көнлек эш нормасын 200—250 процент итеп үтәү йөкләмәсен алды.

«Сталинец» редакциясенең элекке работнигы лейтенант Кузнецов үз подразделениесенең уңышлары турында завод коллективына хәбәр итте. Ул болай дип язды: «Без, барыннан да элек, подразделениебездә снайперлык хәрәкәтен яхшы итеп җәелдерү белән, снайперлар санын арттыру белән үзебезне аеруча күрсәттек. Безнең снайперлар аз гына вакыт эчендә 38 фашистны юк иттеләр».

Н-че часть сугышчылары һәм командирлары «Сталинец» газетасында фронт белән тылның сугышчан ярышы турындагы материалны митингта укып чыкканнан соң, фашист кабахәтләрне кыру турында үзләренә яңа йөкләмәләр алдылар. Бу йөкләмәләр уңышлы төстә үтәләләр. Шушы көннәрдә иптәш Максимов расчеты бер группа фашистларны күрде һәм аларга миномёттан ут ачты. 25 фашист юк ителде.

Фронтовиклар белән завод коллективы арасындагы бу ярыш көннән көн киң җәелә бара.

Турыдан-туры әйтергә кирәк: «Сталинец» газетасының бу ярышны оештырудагы роле гаять зур.

Фронт белән тылның ярышы фронтовикларның һәм эшчеләрнең рухын тагын да күтәрә, аларга яңа көч һәм энергия бирә, дошманны тар-мар итү бурычын уңышлы башкаруга булышлык итә.

А. ТАЛАНИНА.

АЛДЫНГЫ АГИТКОЛЛЕКТИВ

Алексеевский районының «Ясная поляна» колхозы агитколлективы үзенең эшен үрнәк булырлык итеп оештырган. Аның җитәкчесе иптәш Леонович агитация эшен колхоз производствосына бәйләп алып баруга аеруча әһәмият бирә. Әгәр дә бригадада, звенода нормалар үтәлмәсә, ул аның сәбәпләрен өйрәнә, аннан соң, шул участокта үзе эшләп, норманы үтәү генә түгел, бәлки арттырып үтәргә мөмкин икәнлекне практикада күрсәтә.

Аның үрнәгендә башка агитаторлар да колхоз производствосында эшләп алдынгылык күрсәтәләр.

Үзен эш белән таныткан иптәш Леонович һәм башка барлык агитаторлар да колхозчылар арасында зур авторитет белән файдаланалар. Алар үткәргән беседалар зур оешканлык һәм активлык белән үтә.

Большевистик агитациянең гүзәл нәтиҗәләре бар, әлбәттә. «Ясная поляна» колхозы игеннәрне урып-җыюны, ашлык сугуны алдынгылар сафында үтәп чыкты һәм дәүләткә ашлык тапшыру эше дә төгәлләнеп килә. Колхозда хезмәт дисциплинасы яхшы. Хезмәт көннәре минимумын һәм нормаларны үтәмәгән бер генә кеше дә юк дип әйтерлек.

Колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзү фондына тагын 40.000 сум средство җыеп тапшырдылар. Шулай ук батыр сугышчыларга яңа ел бүләге итеп күп кенә җылы киемнәр әзерләп җибәрделәр.

Ф. ХӘМЗИНА.
ВКП(б) райкомы пропагандисты.

ПАРТИЯ САФЛАРЫНА КЕРӘЛӘР

Партком секретаре урынбасары иптәш Закиров булган Н-че заводта, соңгы айларда партия сафларына кабул итүне сорап гариза бирүчеләрнең саны тагын да артты. Заводның алдынгы кешеләре—стахановчылар, икейөз процентчылар, инженер-техник работниклар үзләрен партия сафларына кабул итүне сорап биргән гаризаларында, бөек Ватан сугышының дәһшәтле көннәрендә партия сафында булырга теләгәнлекләрен язалар.

Ремонт-механика мастерское токаре иптәш Курцев ВКП(б) членлыгына кандидат итеп кабул ителде. Ул заводның кадр эшчесе. Иптәш Курцов иң катлаулы заказларны айдан-айга арттырып үтәп, бер ярым һәм ике норма бирә. Бер вакыт иптәш Курцовка бер моторга ремонт ясауны 22 сәгать эчендә башкарырга задание бирелә. Ә ул аны 10 сәгать эчендә башкарып чыга.

Икейөз процентчы бригадир Дергунов, плановик-нормировщик Алеева, слесарь Коловская, цех начальниты орденлы Абрамов, икейөз процентчы Шәнгәрәев, акфиннарга каршы сугышта «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнгән Макаров һ. б. иптәшләр ВКП(б) сафларына кабул ителделәр.

В. ОРЕШНИКОВ.

Кызыл Армиянең XXV еллыгын производствода яңа җиңүләр белән каршылыйк!



«Спартак» комбинатында мастер иптәш Ягудкин җитәкчелегендәге яшьләр бригадасы сталинчыл вахтага басты һәм завод күләмендә күчмә Кызыл Байрак яулап алды. Рәсемдә: иптәш Ягудкин яшь эшченең эшен тикшерә.

К. Тахтеев фотосы.

Күтәренке рух белән

БАЛТАЧ, 8 январь. (Телефон буенча). Иптәш Сталинның котлау телеграммасы уңае белән районның барлык колхозларында да күп кешеле митинглар, җыелышлар булды.

Сталин исемендәге колхозда митинг аеруча зур активлык белән үтте. Колхозчы иптәш С. Бәдриев үзенең чыгышында болай диде:

— Минем ике улым фронтта. Үзем колхозда умартачы булып эшлим. 1942 нче елда бал алу планын 200 процентка үтәдем. Иптәш Сталинның котлау телеграммасына җавап итеп мин быел тагын да тырышыбрак эшләргә һәм бал алу планын 300 процентка кадәр үтәргә сүз бирәм. Танклар колоннасы төзүгә моннан элек акча биргән идем инде. Мин бу төзелешкә тагын 1.000 сум бирәм һәм үзем белән ярышка иптәш Салаховны чакырам.

Иптәш Салахов бу чакыруны кабул итте һәм шунда ук танклар төзү колоннасына 2.000 сум акча кертте. Колхоз стахановчысы 73 яшьлек Исхак бабай Ибраһимов та 3.000 сум акча бирде. Тик шул җыелышта гына да танклар төзү колоннасына Сталин исемендәге колхоз членнары 29.500 сум акча җыйдылар һәм алар үзләре белән ярышка күрше «Кызыл ил» колхозы членнарын чакырдылар.

Сталин исемендәге колхозда соңгы көннәрдә язгы чәчүгә әзерлек эше дә сизелерлек дәрәҗәдә көчәйде. Тик соңгы көннәрдә генә дә басуга 100 тонна тирес чыгарылды, 25 центнер көл җыелды. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт та уңышлы бара.

«Кызыл көч» колхозы да иптәш Сталинның телеграммасына җавап итеп, язгы чәчүгә әзерлек эшләрен киң җәелдерде. Биредә язгы чәчү вакытында кирәк булачак 27 арбага, 48 тырмага, 13 сабан, 9 культиватор һәм 2 чәчү машинасына ремонт ясалган инде. Тимерче иптәш Гыйльметдинов соңгы көннәрдә норманы һәркөнне 200 процентка кадәр үти. Атларны язгы чәчүгә әзерләү эшенә бигрәк тә нык әһәмият бирелә. Колхоздагы 75 эш атының 58 е яхшы көрлектә, калганнары уртача көрлектә. Чәчү орлыклары барлык культуралар буенча җитәрлек күләмдә әзерләнгән һәм алар коры урыннарда саклаланалар.

Г. ГАЙНЕТДИНОВ.

КЫЗЫЛ БАЙРАКЛЫ ЗАВОДЛАРДА

Баш инженерлары Корнеев һәм Зафьянцев булган заводларның коллективлары ноябрь ае йомгаклары өчен Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл Байракларын яулап алганнар иде. Бу бөек бүләк эшчеләрне, инженер-техник работникларны, хезмәткәрләрне тагын да күбрәк көч биреп эшләүгә, фронт өчен чын-чыннан фронттагыча героик хезмәткә рухландырды. Нәтиҗәдә алар декабрь аенда яна җиңүләр яулап алдылар. Бу айда темплар тагын да кызурак булды, фронтка продукция бирү артты. Бөтенсоюз социалистик ярышының декабрь ае йомгаклары өчен, бу үрнәк эшләүче заводлар, ВЦСПС һәм Наркомат карары нигезендә, Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл Байракларын үзләрендә саклап калдылар.

Шушы уңай белән, һәм шулай ук Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган ярышны җәелдерү турында 172 нче номерлы заводның мөрәҗәгате уңае белән, цехларда, участокларда гаять зур күтәренкелек белән митинглар үтә.

Алдынгы заводларның коллективлары күчмә Кызыл Байракны алда да үзләрендә саклап калырга, 1943 нче елда тагын да яхшырак эшләргә, Кызыл Армиянең 25 еллыгын яңа, зур җиңүләр белән каршыларга сүз бирәләр, үз эсләренә өстәмә йөкләмәләр алалар.

Баш инженеры Корнеев булган завод, мәсәлән, Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә багышланган ярышка бердәм рәвештә кушылып, яңа йөкләмәләр алды. Алар арасында, Кызыл Армиянең бөек еллыгы көненә планнан тыш 6 комплект изделие эшләп чыгару, хезмәт җитештерүчәнлеген 10 процентка күтәрү, кара һәм төсле металларга бернечә тонна экономия ясау һ. б. кебек пунктлар бар.

— Алынган йөкләмәләрне намус белән үтәрбез һәм арттырып үтәрбез. Һөҗүм итеп баручы Кызыл Армиягә куәтле, дәһшәтле кораллар бирүне һаман арттыра бару өчен көчләребезне һәм вакытыбызны һич тә аямабыз!—диләр Кызыл Байраклы заводларның эшчеләре.

МЕТАЛЛИСТЛАР ЙӨКЛӘМӘСЕ

Н-че заводның металлистлары 1942 нче елда уңышлы эшләп, айдан-айга планнарын үтәп бардылар. Уннарча эшчеләр сменасына икешәр-өчәр норма биреп эшләделәр. Мондыйлардан орденлы токарь Филинов, орденлы слесарь Мальцев, фрезеровщик Николаев, Хәйруллин, Газизов һәм башка иптәшләрне күрсәтергә мөмкин. Фронт заказларын үтәгәндә алар икешәр-өчәр смена цехтан чыкмый эшләделәр.

Хәзер, 172 нче завод коллективының мөрәҗәгатенә җавап итеп, Н че заводның металлистлары үзләренә яңа йөкләмәләр алдылар. Алар 1943 нче елның беренче квартал планын 25 нче мартка төгәлләргә, эшләп чыгарылган продукциянең үзенә төшү бәясен планда күрсәтелгәнгә караганда 10 процентка киметергә, хезмәт җитештерүчәнлеген планда күрсәтелгәнгә караганда 25 процентка күтәрергә, металл эшкәртү һәм коюбуенча агымдагы бракны 10 процентка киметергә булдылар.

Металлистлар индивидуаль өйрәтү һәм иң яхшы стахановчыларга беркетү белән 1943 нче елның беренче кварталында кимендә III нче разрядтагы 10 токарь, 20 слесарь, 6 формовщик әзерләргә сүз бирделәр. I нче кварталда уйлап табу һәм рационаллаштыру тәкъдимнәреннән 1 миллион сумлык эффект бирергә йөкләмә алынды.

Барлык пунктлар буенча металлистлар күршедәге кою-шлифовка цехы коллективын социалистик ярышка чакырдылар.

КОЛХОЗЛАР ӨЧЕН КАДРЛАР

КУКМАРА, 8 январь. (Телефон буенча). Яниль МТС ы каршында кырчылык бригадирлары әзерләү буенча курс оештырылган иде. Курс 15 көн дәвам итте. Анда 39 кеше укып чыкты. Хәзер тагын 33 кешедән кырчылык бригадирлары һәм 31 кешедән колхозлар өчен агротехниклар өчен курс оештырылды.

Колхоз картларыннан

ЧҮПРӘЛЕ, 8 январь. (Телефон буенча). Республикабызның колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына иптәш Сталинның җибәргән телеграммасы һәм Кызыл Армиябез тарафыннан явыз дошманга бирелә торган каты ударлар колхозчыларны фронтка ярдәм итүне тагын да көчәйтүтә рухландырды. Шушы уңай белән барлык колхозларда да митинглар, җыелышлар булды.

«Көрәшче» колхозы членнары митингта ук Кызыл Армия фондына 20 сарык, 30 каз, 16 килограмм май, 17 тире, ике сарык тушы һәм 25 мең сум акча бүләк иттеләр. Колхоз картлары бу эштә аеруча якыннан катнашалар. Менә 70 яшьлек Гыймади бабай Мистаков. Аның бер улы армиядә. Ул дәһи юлбашчыбыз иптәш Сталинның телеграммасына җавап итеп, Кызыл Армиягә бер сарык, бер каз бирде. Аның кордашы Салихов бабай да аннан калышмады: 3 каз һәм бер сарык тиресе бүләк итте. Хәлилов бабай 2 каз, май, сарык тиресе һәм 300 сум акча, Юнус бабай бер сарык һәм бер каз бирде.

Язгы чәчүгә әзерлек

Биектау районының «Новое Мамонино» һәм «Кызыл байрак» колхозлары язгы чәчүгә сугышчан төстә әзерләнәләр. Бу колхозларда ашлык сугу, дәүләткә ашлык тапшыру һәм язгы чәчү өчен орлык туплау планнары күптән үтәлде инде.

«Новое Мамонино» колхозында язгы чәчү өчен кирәкле инвентарьларга ремонт ясау да тәмам булды инде. Хәзер колхозчылар көл, кош тизәге һәм башка җирле ашламаларны җыялар.

«Кызыл байрак» колхозында да сабаннарга, тырмаларга һәм культиваторларга ремонт бара. Кош тизәге, көл һәм башка шундый ашламалар һич тә әрәм ителмичә җыела.

Иптәш Сталинның республикабыз колхозчыларына җибәргән котлау телеграммасы белән рухланып, «Кызыл байрак» колхозы членнары да үз хуҗалыкларындагы запастан Кызыл Армия фондына 90 центнер ашлык бирделәр.

ТАГЫН ДА ЯХШЫРАК ЭШЛӘРГӘ

1 нче мех фабрикасының эшчеләре, инженер-техник работниклары яңа елны производствода зур уңышлар белән каршыладылар. Коллективның алдынгы кешеләре алган йөкләмәләрен үтәп чыктылар, шуның белән илебез алдындагы, Кызыл Армия алдындагы бурычларны үтәделәр.

Иптәш Лапанина бригадасы декабрь ае планын 135 процентка үтәргә йөкләмә алган иде. Фронт таләп иткәнчә эшләү нәтиҗәсендә бригада айлык планны 150 процентка үтәп чыкты. Кожевникова һәм Гайнетдинова иптәшләрнең бригадалары да алган йөкләмәләрен 10 процентка арттырып үтәделәр.

Скорняк цехы машинисткалары Нигъмәтуллина, Фонəркова, Хәмидуллина, портниха Колосова, венгерщица Скорнякова, Гыйльметдинова иптәшләр декабрь ае планын 130—150 процентка үтәргә йөкләмә алган булсалар, алар үзләренә тапшырылган заданиене 200—270 процентка үтәп чыктылар. Иптәш Баһаветдинова декабрь аенда производство программасын 310 процентка үтәде.

Тире юу машинасында эшләүче Лимонова, строгаль Солдатенкова, наборщица Богатырева, машинистка Мөслимова, тегүче Батырова һәм скорняк Хафизова иптәшләр декабрь аенда системалы рәвештә ике-өч норма биреп эшләделәр.

Фабрика коллективы, узган елдагы уңышларын ныгытып, быел тагын да яхшырак эшләргә омтыла.

Г. ТАҖИЕВА.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

8 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

8 нче январьда безнең гаскәрләр каты сугышлардан соң Зимовники шәһәрен һәм тимер юл станциясен алдылар.

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр, һөҗүмне дәвам иттереп, халык яши торган **Новый Мир, Алексеев, Медвежка, Нижний Вязовый, Верхний Вязовый, Федоровка, Владимиров, Беляев, Чумаков, Кумшак** пунктларын алдылар.

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр халык яши торган **Ново-Павловская** район үзәген, халык яши торган пунктлардан **Никольскоены; Горькая Балканы, Правокумскийны, Сизовны, Ново - Срединйны; Матигоринскийны, Орловскины; Старо-Марьинскийны, Псыхурейны, Марьинскаяны; Кубаны** һәм тимер юл станциясе **Зольскийны** алдылар.

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

7 нче январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 5 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 150 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 9 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 6 сугыш припаслары складын шартлаттылар, ике ротага якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең штурм отрядлары дошманның 9 блиндажын кулга төшерделәр һәм бер ныгытма үзелын чолгап алдылар. Иптәш Ячкевич командалыгындагы орудие расчеты, туры атып, немецларның бер частеның штабын җимерде. Сталинградтан төньяк-көнбатыштарак безнең сугышчылар 16 окопны алдылар, 300 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын кырдылар, 2 танкны сафтан чыгардылар, 13 пулемет һәм 64 винтовка кулга төшерделәр.

* * *

Донның түбәнге агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Дошман каты каршылык күрсәтә һәм еш кына контратакаларга күчә. Безнең частьлар гитлерчыларның барлык контратакаларын кире кайтардылар һәм сугышлар нәтиҗәсендә халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Халык яши торган бер зур пункт янында немец танклары безнең пехотабызга каршы бер-бер артлы 3 контратака ясадылар. Артиллеристлар һәм бронебойщиклар немецларны җимергеч ут белән каршыладылар, дошман танкларына совет гаскәрләренең сугышчан сафларына якынлашырга мөмкинлек бирмәделәр. Безнең сугышчылар, артиллерия уты ярдәме белән, халык яши торган пунктка бәреп керделәр һәм аны саклаучы гарнизонны тар-мар иттеләр. 600 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Дошманның 9 танкысы яндырылды һәм зарарланды. 7 орудие, 24 пулемет, 16 автомашина, 2 радиостанция һәм башка трофейлар кулга төшерелде. Икенче бер участокта Н-че берләшмә сугышчылары халык яши торган 3 пунктны алдылар һәм күп трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр үзләре алган позицияләрне ныгыттылар, ә көчләренең бер өлеше белән дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Н-че часть сугышчылары немецларның бик күп пехотасының һәм танкларының контратакасын кире кайтардылар, 200 гә якын гитлерчыны кырдылар һәм 3 самоход орудиене юк иттеләр. Икенче бер участокта немецларның моторлаштырылган пехотасы һәм танклары безнең гаскәрләр урнашкан урынга үтеп керә алган иде. Совет частьлары, контрудар ясап, гитлерчыларны алып ташладылар һәм аларны куып барып, дошманның ныгытылган позицияләрен алдылар. Немецларның 2 танкысы һәм бер ротага якын гитлерчылар юк ителде. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Төньяк Кавказда совет гаскәрләре, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, сугыша-сугыша алга бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер участокта совет танкистлары немец частьларының сугышчан сафлары аркылы үтеп чыктылар һәм гитлерчыларга тылдан һәм флангларда атака ясадылар. Сугыш нәтиҗәсендә 400 дошман солдаты һәм офицеры юк ителде. 80 автомашина, 50 миномет, күп винтовкалар, пистолетлар һәм сугыш припаслары кулга төшерелде. Пленныйлар алынды. Икенче бер участокта Н-че часть халык яши торган бер пунктны алды һәм бик күп трофейлар кулга төшерде. Шулар арасында 19 танк, 110 автомашина, 26 пулемет; азык складлары һәм әйберләр тутырылган 3 склад бар.

* * *

Украина партизаннарының бер отряды актив сугыш хәрәкәтләренең бер ае эчендә 200 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырган. Партизаннар бер тимер юл станциясенә барып кергәннәр һәм ягулык тутырылган 12 цистернаны шартлатканнар. Шуның өстенә совет патриотлары аэродромда немецларның 2 самолетын юк иткәннәр һәм 3 складны яндырганнар. Икенче бер отрядның партизаннары, немецларның хәрби эшелоны үтеп барган чакта бер күперне шартлатканнар. Паровоз һәм 12 вагон җимерелгән.

* * *

8 нче январьда Берлин радиосы, түбәндәге хәбәр белән радио тыңлаучы немецларны шак катырды: «7 нче январьда кич белән Берлинда Көнчыгыш Кавказдагы Германия гаскәрләренең, алга чыгып тора торган терәк пунктларны алу юлы белән, фронт линиясен кыскартулары мәгълүм булды. Германия арьегардларына каршы советларның атакалары, сугышка бик күп танклар кертүләренә дә карамастан, уңышсыз чыкты».

Һәркемгә мәгълүм, Төньяк Кавказда берничә көн барган һөҗүм вакытында Кызыл Армия сугыша-сугыша 110-130 километр алга китте, Алагир, Ардон, Малгобек, Моздок, Нальчик, Прохладный, Майское шәһәрләрен һәм халык яши торган күп кенә башка әһәмиятле пунктларны һәм тимер юл станцияләрен алды, шулай ук бик күп санда трофейлар кулга төшерде һәм пленныйлар алды. Ә менә Берлинда Гитлер гаскәрләренең Төньяк Кавказда чигенүләре 7 нче январьда кич белән генә билгеле булган икән. Әлбәттә, Төньяк Кавказда немецларның чигенүе Гитлер командованиесенә күптән ук билгеле инде, ләкин ул, Германия халкына дөреслекне әйтергә теләмәгәнлектән, бу турыда озак вакытлар дәшми килде. Ә инде чигенү турында артык дәшми торырга мөмкин булмый башлагач гитлерчы идарәчеләр бу турыда дәшәргә, ләкин һаман да беркем дә бернәрсә дә аңламаслык итеп дәшәргә карар биргәннәр, ягъни тагын ялганлаганнар.

Гитлер шарманщикларының «Фронт линиясен тигезләү» турындагы җырлары да шулай ук яңа нәрсә түгел. Үткән елгы кыш һәркемнең хәтерендә. Ул чагында Кызыл Армия немецларның Москвага ясаган атакаларын кире кайтарып, һөҗүмгә күчте, немец гаскәрләрен куды һәм урыны-урыны белән 400 километрдан артыграк алга китте. Менә шул чагында инде гитлерчылар «фронт линиясен тигезләү турында» беренче тапкыр сөйли башладылар. Хәзер инде Кызыл Армия немец-фашист гаскәрләргә тагын куәтле ударлар ясый һәм аларны Көнбатышка алып ташлый. Үткән елгы шикелле үк, бу юлы да гитлерчылар фронт линиясен кыскарту турында мыгырдый башладылар. Иске көй яңа ладка салынды. Чынлыкта исә Төньяк Кавказда, шулай ук фронтның башка участокларында да, фронт линиясе Гитлер командованиесенең теләгенә һәм планнарына каршы килеп, Кызыл Армия инициативасы белән үлчәнә.

Кызыл Армия ударлары астында чигенгән чакта немецлар фронт линиясен тигезләү турында такылдыйлар, ләкин башында акылы булган һәрбер кеше хәзер инде белә: гитлерчы идарәчеләр фронт линиясен тигезләү турында сөйлиләр икән, димәк, немецлар чыннан да авыр хәлдә.

„КЫЗЫЛ АРМИЯ ИНИЦИАТИВАНЫ ҮЗ КУЛЫНА АЛДЫ,

Совет гаскәрләренең һөҗүме турында Америка матбугаты

НЬЮ-ЙОРК, 7 январь. (ТАСС). Кызыл Армиянең һөҗүме Америка Кушма Штатларының киң катлау халыклары арасында гаять зур кызыксындыру тудыруда дәвам итә. Газеталар һәм радио Совет—Германия фронтыннан алынган соңгы хәбәрләргә гаять зур әһәмият бирәләр. Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәрби күзәтүчесе Бэбб совет гаскәрләре тарафыннан Моздокның алынуы турындагы хәбәргә аңлатма биреп болай яза: «Германия командованиесе, һичшиксез, Төньяк Кавказдагы гаскәрләренең позицияләре нык булмауга җитди рәвештә борчыла. Совет гаскәрләре тарафыннан Великие Лукиның алынуы да шулай ук зур әһәмиятле урын тота. Немецлар Великие Лукины үзләренең төп крепостьларыннан берсенә әйләндергәннәр иде. Бу крепость барлык ресурсларны һәм Германиянең хәрби-инженерлык сәнгате кулында булган барлык мөмкинлекләрне файдалану юлы белән ныгытылды, һәм немецлар аны бик каты сакларга тырыштылар. Великие Лукиның алынуы Германиянең бик нык саклана торган ныгытылган пунктларына да Кызыл Армиянең җимергеч ударлар бирергә сәләтле икәнлеген тагын бер тапкыр күрсәтте».

«Нью-Йорк таймс» газетасы да Великие Лукиның алынуы зур әһәмияткә ия булганлыгын күрсәтә. «Бу шәһәр Германия оборона линиясенең бик каты ныгытылга пунктларыннан берсе иде. Великие Лукиның алынуы зур әһәмиятле урын тотка лыгы турында шуның белән дә фике йөртергә мөмкин: Германия командовани се бу фактны Германия халкыннан яшер Немецлар Великие Лукины алынмаслы крепость дип санаганнар иде, ләкин хәз русларның көчләре шул кадәр үсте к алар бу пунктны алырга булдыра а дылар».

«Нью-Йорк таймс» газетасының хәрб күзәтүчесе Болдуин—Моздокның, Про ладная һәм Нальчикның алынуы стратеги ягыннан бик зур казаныш булып тор дип күрсәтә. Кызыл Армиянең быелг кыш көнендәге һөҗүм операцияләрен у ган кышкы һөҗүм операцияләре белә чагыштырып, Болдуин болай ди: «Бу кы Кызыл Армия үзенең һөҗүм операциялә рен алданрак башлады һәм узган ел караганда тизрәк алга хәрәкәт итә. Кызы Армиянең алга баруы хәзер үк инд Германиянең әһәмиятле коммуникациял ренә җитди куркыныч тудырды».

«Стар» газетасы болай яза: «Кызыл Ар миянең һөҗүм операцияләренең уңышлы булуы шуннан килә ки, бу һөҗүм бик як шы итеп әзерләнгән. Бу әзерлек Советла Союзы дусларының гына түгел, бәлк аның дошманнарының да көткәннәреннә күп тапкырлар югарырак булып чыкты».

Антонеску „хөкүмәтенә" каршы заговорның ачылуы

ЛОНДОН, 7 январь. (ТАСС.) Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Антонеску хөкүмәтенә каршы тимер гвардиячеләрнең заговоры ачылганнан соң Румыния полициясе 4.000 нән артык кешене кулга алган. Кулга алынучылардан 80 кешегә үлем җәзасы бирелгән инде. Тимер гвардиянең элекке башлыгы Хориа Сима Италиядән Румыниягә кайтып килгән вакытта кулга алынган. Ул анда восстаниегә җитәкчелек итү өчен Германиядән барган булган.

«Базлер нахрихтен» газетасының хәбәр итүенә караганда, кулга алынучылар арасында Румыниянең элекке баш министры һәм милли царанислар партиясенең лидеры Юлиус Манну, Хориа Симаның хатыны һәм Румыниянең Римдагы элекке илчес Божан да бар. Заговорга шулай ук кү кенә дәүләт чиновниклары да катнашка булганнар. Күчәр державаларының гаскәрләре Бухарест урамнарын саклыйлар. Стратегия ягыннан әһәмиятле булган барлы пунктларга пулеметлар куелган. Тимер юлларны һәм шоссе юлларын бик җентекләп күзәтеп торалар. Барлык җәмәгать биналары ябылган. 23 сәгатьтән соң урамнарда йөрү туктатыла. Румыния чикләрендә тагын да катырак саклык чаралары кертелгән.

ФРОНТТАН ХАТ

Кыска эпизодлар

III. ТИМЕР МИЧ ЯНЫНДА

...Шундый яхшы нәрсә ул тимер мич! Шундый якын дус ул безгә монда! Юк, мич турында болай гына, гади сүз белән генә әйтеп булмый. Гөрли-гөрли яна ул, мин сиңа әйтим, кып-кызыл булып, тирә-якка нур чәчеп, блиндажга әсселек һәм җылылык биреп, дөрли-дөрли яна ул. Ә аның өстендә чыж-чыж килеп котелок белән чәй кайный... Яз һәм көзнең яңгыр-җилле салкын көннәрендә дисеңме, кышкы җил-давыллы, кар-буранлы озын салкын төннәрдә дисеңме, чатыр-чатыр килеп, җанга рәхәт биреп, гөрли-гөрли яна ул. Тышта җил улый, кара урман улый, ә блиндажда тыныч һәм рәхәт. Карлы урман киңлегенә төтенен туздырып, төпләрендә кып-кызыл күмерен калдырып, көн дими, төн дими һаман яна ул...

... Татар егете разведчик Исхак Мостафин, каравыл сменасын бетереп, якын иптәше, бердән-бер якташы Камил Максудов янына, күрше взвод блиндажына килде. Алар икәү бергә, калын гына итеп махра төрделәр, гөрләп янып торган тимер мич янында Камилнең өйдән алган хатын укып чыктылар. Сүз анда китте, монда китте, «сөйләсәң сүз, тартсаң күз чыга» дигәндәй, сүз каршыда гөрләп янып торган тимер мичкә килеп җитте. Исхак зарлана башлады:

— Безнең мич бик кәй, малай. Төтәп утыра шунда, чәчрәп беткән нәстә. Рәтесыны юк—ул үзләренең мичләрен яманлый-яманлый сөйләнергә тотынды. Чынлап та аларның мичләре начар иде, аларның мичләре патроннардан бушаган калай тартмалардан ясалган, мичкә ошаш дүрт катлы бер нәрсә иде.

— Менә әйтте дип әйтерсең чәчрәп бетим, яңадан разведкага барам икән, немец йөзе караларның бер тимер мичләрен әләктерәм дә кайтам. Әләктереп кайтам дигәч—кайтам! Әйтте дип әйтерсең!

Ул шулай берничә минут сөйләшеп торды да, хушлашып чыгып китте. Камил исә, үзенең өйдән алган хатын йөздә өченче кат укый-укый мич янында калды.

Бер дә бер көн Исхак, бер төркем сугышчылар белән бергә, дошман тылына барырга һәм аннан ничек булса да контроль пленный—«тел» алып килергә сугышчан задание алды. Командир аңа төнлә кузгалырга тәкъдим итте.

Төн тын һәм матур иде. Йолдызлар күктә күз кысып, көмеш нур сирпи иде. Разведчиклар, ике группага бүленеп, каршыда торган немец блиндажына таба шуыштылар. Эш гаять уңышлы чыкты. Алар тавышсыз-тынсыз гына үрмәләп килеп, блиндаж янында сакта торган немец солдатын арттан тотып алып, башын плащ-палатка белән каплап, авызына чүпрәк тыгып, таза җеп белән кулын артка бәйләп, разведчиклар, үз якларына юнәлделәр. Исхак өчен бөтәрәк тә эш уңышлы чыкты. Ул немец блиндажының эченә керде, өстәл өстеннән кәгазь, сумка кебек нәрсәләрнең барысын да учлап кесәсенә тыкты, һәм бер читтә, сүнеп беткән, акрын гына пыскып торган тимер мичне иңсәсенә салды да, иптәшләрен куып җитте.

Камил дусты Исхак янына килде. Блиндаж эченә керү белән үк, блиндаж уртасында гөрли-гөрли янган тимер мич аның күзенә чалынды. Ул мич янына килде, мичнең капкачын ачты, аннан «Тула» дигән сүзне күреп калды һәм дустын үртәргә тотынды:

— Әй Исхак! Шулмы мичең? Бу бит немец миче түгел, безнең чын-чын совет миче!

— Юк инде, агай-эне! диде Исхак, —куркак булсаң, куркак бул. Без нәстә өчен сугышабыз соң? Син акыш-макыш төсле сүлисең, агай-эне! Без үзебезнең хәләл хакны кире алу өчен сугышабыз ла баса! Тимер мичтән зуррак нәрсәләребез дә алар кулында бит әле. Әйдә утыр, әйбәт кенә итеп чәй эчеп җибәрик әле!

ШӘРӘФ МӨДӘРРИС.

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

◇ Греклардан 300 кеше богауланып заложниклар сыйфатында Италиягә җибәрелгәннәр. Аларның кулга алынуларына Грециядә партизаннар хәрәкәтенең көчәюе сәбәп булган.

◇ 1942 нче елда АКШ та 8.090.800 тонна авырлыгында 746 корабль төзелгән. Кораллы көчләр өчен эшләнгән корабльләр һәм 500 данә кечерәк пароходлар бу исәпкә керми.

Җаваплы редактор урынбасары **ГАЛИМ РЯБКОВ.**

ПФ 812 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «ҚЫЗЫЛ ТАТАРСТАН издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 36